
Тылсымлы Сәхифәләр

# Мактанчык чыпчык





М16 УДК 821.512.145
ББК 84.2
ISBN 978-5-906508-16-4

Тылсымлы сәхифәләр

Абдулла Алиш әкияте буенча

# Мактанчык чыпчык



Татармультфильм

Издательство «Татармультфильм»



Тәрәзәгә каршы бер озын колга сузылган. Ул колгага нарат такталардан эшләнгән оя куелган. Әле кичә генә балалар ул ояны ашыга-ашыга эшләп бетерделәр, ә бүген инде анда яз кунаклары — сыерчыклар килделәр. Ояның эчен-тышын җентекләп карадылар, бик ошаттылар. Аны ясаучыларга рәхмәт укыдылар, матур итеп сайрап куйдылар.

Сыерчык оясына каршы тәрәзә башында бер карт Чыпчык утыра. Ничә еллардан бирле инде ул шунда тора. Салам-солымнарны, йон-мамыкларны җыеп, оя ясаган. Салкыннар килгәч тә, җылы якларга очмаган, шул ояда кышлаган ул Чыпчык.

Яңа кунакларны Чыпчык нишләптер кәефсез каршы алды.

— Күңелсез иде, күршеләр булды, — дип, эченнән бераз шатланды.



Ә үзе:


— Сайраулары белән колакны тондырып бетерерләр, рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмәсләр, туктагыз дисәң дә, туктамаслар, күрше димәсләр, — дип уйланды.

Чыннан да, шулай булып чыкты. Сыерчыклар монда Чыпчык абзый яши дип тормадылар, көне буе өзелеп-өзелеп сайрадылар.

Чыпчыкның моңа бик ачуы килде, ямьсез тавыш белән күршеләренә җикеренде:

— Бөтен тынычлыгымны боздыгыз, сайраган булып, колагымны тондырдыгыз. Ичмасам, чыпчыклар төсле сайрый алсагыз икән, алардан да уздырсагыз икән... Безнең җырны бар тавыклар хәйран калып тыңлый, безне хуҗа да бик зурлый...

Сыерчыклар мактанчыкның бу сүзләрен ишетеп аптырап калдылар. «Бу әллә юләрме икән?» — дип уйлап алдылар.



Җае чыккан саен, Чыпчык мактана бирде. Әй мактады чыпчык-ларны — күкләргә чөерде. Имештер, дөньяда алардан батыррак бар микән, имештер, аларның өйләрен берәү дә җимерә алачак түгел. Көчле давыл гына булсын, имеш, сыерчыклар оясы беркетелгән колга сыначак, оя йөзтүбән капланачак.

— Күрербез әле ничек булганын, кем отылганын, — дип җавап бирделәр сыерчыклар.





Беркөнне Чыпчык үз өенә атылган уктай кайтып керде. Аның артыннан күктә, биектә, Карчыга күренде.

Батыр Чыпчыкның кемнән куркуын сыерчыклар бик яхшы белделәр.

— Батырның тавышы-тыны юк, өенә бикләнде, ахры, — дип көлделәр.

Бераз яткач, Чыпчык оясыннан башын чыгарды, күршеләренә сүз салды:




— Күрдегезме Карчыга белән минем ничек сугышканны? Әй бирдем дә соң үзенә, утлар күренгәндер күзенә! — дип сөйләнде.

Сыерчыклар бер сүз әйтмәделәр, мактанчыкның кәефен җибәрмәделәр.



Берзаман Чыпчык һәрвакыттагыча мактанып тора иде:

— Хуҗа Песиенең күзен чукыдым, әй кирәген бирдем... Сыерчыклар аның сүзен тыңлагандай иттеләр, ләкин соңыннан әйттеләр:




— Ул Песине әле бая гына күрдек, күзләре дә бик исән, мыраулап йөридер иде, — диделәр.

— Юк, юк, күршеләрнекен күргәнсездер, ә безнең хуҗаныкы инде сукыр, безгә һөҗүм итәргә куркыр, — диде Чыпчык.



Ә шулчак әлеге Песи, посып кына, өй кыегы буйлап тәрәзә башына таба үрмәләде. Мактанчык Чыпчык, арты белән торганга, аны күрмәде. Мәче инде Чыпчыкка якынлашты.

Сикереп, тегене эләктереп алмакчы иде, шулчак сыерчыклар очып килеп җиттеләр. Песинең күзен чукып җибәрделәр, аны кире чигендерделәр. Песи өй кыегыннан чормага сызды.



Мактанчык Чыпчык куркуыннан калтырап төште, сүз дә әйтә алмады.

Кинәт ул телгә килде һәм болай диде:

— Ярый, бәхете бар икән, китеп котылды, күрмәгәнен күргән булыр иде!



Сыерчыклар тагын көлделәр һәм аңа болай диделәр:

— Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә!




## Художественно-анимационное издание

Абдулла Алиш әкияте
Сказка Абдуллы Алиша

Руководитель проекта **Азат Ганиев**
Литературные редакторы **Анна Белоброва, Алсу Марданова**
Художественный редактор **Дамир Бариев**
Художник **Гузель Гилазетдинова**
Компьютерная вёрстка **Дамир Бариев**
Главный режиссёр **Сергей Киатров**
Анимация **Художники-мультипликаторы объединения «Татармультфильм»**
Технический директор **Марат Башаров**

Печать офсетная
Заказ №
Отпечатано с готового оригинал-макета
издательства «Татармультфильм»
в типографии ООО ПО «Промполиграф».

© Объединение «Татармультфильм»



www.tatarmultfilm.ru

ISBN 978-5-906508-16-4